**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” ноябрь 2025 ел. № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

-Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен яктырткычлар, проводлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);

-Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу, Күәм авылы территориясен чистарту, агачларны, куакларны кисү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (Күәм авылының Космодемьянская һәм Ленин урамындагы чишмә территорияләрен чистарту һәм төзекләндерү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Күәм авылындагы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү өчен вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Күәм авыл башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

2025 елда янга калдырылган үзара салым акчаларының калдыгын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Сәмигуллин Л.Ә.